ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 31.07.2024 1119 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү һәм күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турында кабул итү комиссиясе тарафыннан актны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 26 июлендәге 1043 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында «Федераль законга һәм «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 19 декабрендәге 608-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү һәм күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турында кабул итү комиссиясе тарафыннан актны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 26 июлендәге 1043 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 1.5 пунктындагы 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпфатирлы йорттагы бинаны яңадан планлаштыру мондый бинаның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртүдән гыйбарәт, һәм (яисә) яңа биналар

барлыкка килү, шул исәптән әлеге Кодексның 40 статьясында каралган очракларда, һәм (яисә) аның эчке планировкасын үзгәртү (шул исәптән аның чикләрен һәм (яисә) урынның мәйданын үзгәртмичә). Урынны яңадан планлаштыру нәтиҗәсендә чиктәш урыннарның чикләре һәм (яисә) мәйданы да үзгәртелергә мөмкин. Планлаштыру чикләр һәм (яисә) урын (урыннар) мәйданы турында яисә төзелгән урыннарның дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыру һәм төзелгән урыннарга хокукны дәүләт теркәвенә алу турында күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестры белешмәләренә үзгәрешләр кертү зарурлыгына китерә.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Э.Р. Әхмәдиева